*Фатыйма Ильская*

# ГОМЕРЛЕК ДУС

Мин Кутуйны 1924 елдан бирле беләм. Беренче тапкыр минем бенифисымда таныштык шикелле. Һади Такташ белән икесе мине бик хөрмәт итеп котлау язганнар иде. Мин Такташның «Җир уллары» трагедиясендә Әкълимәне уйнадым. Шуннан башланган дуслык гомер буе дәвам итте.

Минем үземнең дә ул чакта бик яшь вакытларым. Кутуй театрны тыштан карап, спектакльләр буенча гына рецензия яза торган кеше түгел. Ул репетицияләргә килеп утыра, спектакльләрне тикшерүдә катнаша, рецензия язасы спектакльне бер генә тапкыр карамый, пьеса куелган саен килә. Репетиция барганда, хәтта тамашачы өчен уйнаганда да сәхнә артына кереп киңәшләр биреп чыга, менә монысы болайрак бит, ди. Ул синең эшеңә үз эше итеп карый, аның теләге бер — рольнең мәгънәсен тулы итеп, дөрес итеп тамашачыга җиткерүдә ярдәм итү. Виктор Розовның «Таня»сын куйганда аның миңа ярдәме бигрәк тә зур булды. Танның кичерешләрен, горурлыгын, рухи үсешен күрсәтергә булыша торган киңәшләр бирде.

Һади Такташ та еш килә иде, ул ничектер театр эшенә читтән карый, җәмәгатьчелек вәкиле булып карый иде. Соңгы елларда Гази Кашшаф театрга бик якынлашты. Ул инде миңа Кутуй урынына ярдәмче булды. Ләкин ул да спектакльгә рецензия язу өчен генә килгән кебек иде. Ә менә Кутуй безнең арада үзен дә артист итеп хис кыла иде. Мин аның «Нәнкә җан»ында Нәнкә җанны уйнадым. Генеральный репетиция вакытында Кутуй сәхнә артына йөгереп кергән. Син нәкъ мин теләгәнне әйтеп бирәсең, син мине шундый дулкынландырдың, мин сине моннан соң Нәнкә җан дип кенә йөриячәкмен, ди. Камал II каршы төшә, ничек инде Фатыйма Нәнкә җан булсын, янәсе!

Кутуй Камал II, Камал III белән дә бик дус иде. Чөнки ул берәр кимчелекне күрсә, шунда ук әйтә, төзәттерә. Гомеремдә Кутуйдан күңелсез сүз ишетмәдем. Елмая, һәркемгә елмая. Артистның уңышына үз уңышына шатланган кебек шатлана. Безнең белән төрле кичәләр оештыра, үзенең әсәрләрен укый, башка язучыларның яңа әсәрләрен укып фикер алышулар оештыра. Аз гына вакыты булдымы, Кутуй — театрда. Хәтта сугыш вакытында фронттан кайтып киткән арада да шулай булды. Бик матур бер концертка конферансье булганы хәтеремдә.

Безнең төркемдә мин, Камал II, Камал III, Габдрахман Минский, Кутуй, Такташ була иде. Галимҗан Ибраһимов Түбән Осланда ял иткәндә аның янына бергәләп баруны да Кутуй оештырды. Юлда үзенең шигырьләрен укып барды.

Мин тагын Кутуйның «Балдызкай»ында Гөлшатны уйнадым. «Нәнкә җан»ны, «Балдызкай»ны без кайларда гына куймадык: Кырымда, Уфада, Ташкентта, тагын әллә кайларда.

Кутуй (мин аны гел Кутуй дип йөрдем, исеме белән дәшми идем) бик яхшы оештыручы иде. Маяковский Казанга килгәч, аның чабып йөрүләре бүгенгедәй хәтеремдә.

Җыелышларда шулкадәр көчле чыгышлар ясый, аннары җыелыштан соң концерт оештыра. Ул бик әйбәт сөйли иде. Мин аңа, сөйләргә синнән өйрәнергә кирәк әле, ди идем. Ул, син ничек өйрәнәсең, син бит — артистка, ди иде. Ул Маяковский әсәрләрен шулкадәр матур укый иде. Радиодан да укый иде аларны, сәхнәдән дә.

Кутуй белән безнең дуслык гаиләләр дуслыгына әверелде. Ул Фәтхи Бурнашны да бик ярата иде. Галимәгә өйләнгәнче, өйләнергә ниятләп йөргәндә, без җыелып Галимәләргә бардык: мин, Камал II, Камал III, Кутуй. Галимә безне пәрәмәч белән сыйлады. Галимә — пәрәмәч остасы. Аның кебек тәмле итеп беркем дә пәрәмәч пешерә алмый. Үзе шундый чибәр: күк төсле зәңгәр күз, алтынсу сары чәч, ап-ак йөз. Үзе яшь кызларда гына була торган тулылык белән былкылдап тора. Тутырган тавык шикелле, диләр инде бездә.

Галимә Хәмдия исемле бер кардәше белән тора иде, Островский урамында. Хәмдия — кара чәчле, кара күзле. Анысы да бик чибәр, икесе дә эшкә бик уңганнар. Кутуй шуларның кайсысын сайлыйм икән дип икеләнеберәкме тора. Үзенең күңеле күбрәк Галимәгә тартыла ахры, тегесе дә бик чибәр. Шул мәсьәләне хәл итү өчен ул анда тагын кемнәрнедер алып барган бугай. Галимәне алып, Камал III ләргә барганым да хәтеремдә.

Гадел Кутуйның гаиләсе матур гаилә булды. Галимә бик гади, намуслы, тырыш хатын. Гомергә ике ставкада эшләде. Балаларны авырлык белән үстерде. Әтиләреннән ваклар калдылар бит балалар. Кайнанасын ярата иде, аңа игътибарлы булды.

Бервакыт мин бик нык авырып киттем. Үпкәң шешкән, диделәр. Бик куркам инде. Менә Галимә килеп керде. «Мин Кутуй белән, ул керсенме?» — ди. Авыру кешенең урын-җире бик җыйнак булмый бит, мин уңайсызландым. Галимә тиз генә мине киендерде, урын-җирләремне алыштырып рәтләде, шулай итеп Кутуйны кертте. Кутуй мине әй юата, әй юата! Менә Галимә пәрәмәч пешереп алып килде, шуны ашыйсың да хәзер тереләсең, ди. Әле мин сиңа «Нәнкә җан»нан да әйбәтрәк пьеса язам, әле син әллә нинди рольләр уйнарсың, ди.

Ул мине һәрвакыт рухландырып, канатландырып тор-

ды. Туганым төсле, минем турыда кайгырта иде. Мин Фәйзи [1] белән дуслашып йөри башлагач та шулай булды. Галимә белән киләләр, җыелышып чыгып китәбез Ирек мәйданына, урамга. Шаярабыз, көлешәбез, кайчак Фәйзи биеп китә, балетмейстер иде бит ул, Кутуй шигырь укый, без я кул чабабыз, я җырлыйбыз, ду килеп йөрибез.

Фәйзине каршына утыртып, беркөнне Кутуй сөйләшкән моның белән: син Фатыйманы чынлап яратсаң гына, әйбәт семья корырлык булсаң гына йөр, дигән. Безнең мөнәсәбәтләрнең озакка бармасын сизгән ахры. Ул шулай бик алдан күрүчән иде. Кемнең нинди буласын алдан әйтеп куя иде, һәм шул дөрескә чыга иде.

Бер чакны шулай боларга килдем. Галимә пәрәмәч пешереп йөри, мин аңа булыша башладым. Кутуй да өйдә. «Нәрсә язасың?» — дим. «Бүген әле ял итәм, берни дә язмыйм»,— ди. Аннары: «Бәлки, әле берәр шигырь дә язып ташлармын»,— ди. Без чәй эчәргә утыргач әйтә: «Кызлар, тыңлагыз әле, бер шигырь яздым»,— ди. Һәм ул чагында «Үземә» [2] дип аталган, соңыннан «Белмиләр» исемендә матбугатта чыккан шигырен укыды. Ул аны күп булса ярты сәгать эчендә язды. Шигырьнең кулъязмасы хәзер дә миндә саклана. «Сиңа багышлап яздым,— диде, аннары өстәп куйды: — Сиңа гына да түгел, үземә, барлык сәнгать кешеләренә». Кутуйның тагын бер шигыре бар иде миндә, анысы сакланмаган шул.

Кутуй минем тормышымны, ялгызлыгымны аңлый иде. Шигырьгә хәсрәт-шатлыкларымны сыйдырган. Тик мин аның мәгънәсен ул чагында рәтләп аңламадым. Соңыннан, тора-бара бу әсәр минем иң яратып укый торган шигырем булып китте. Мин аны һәр концертта диярлек укый идем.

Ничектер күтәренке күңел белән яшәдек без. Тормышта кызыклар бик күп була иде. Миңа яңа квартира бирделәр. Анда ванна бар. Ул чагында мунчада кеше күп була иде бит. Кутуйлар семьялары белән миңа юынырга киләләр. Бер чакны шулай алар килгәндә мин пилмән пешергән идем. Ул көн шул кызыклыгы белән истә калган. Галимә чәчен ромашка белән юа иде. Ул көнне ромашкасы юк. Мин әйтәм: «Кызыл стрептоцид белән ю, мә»,— дим. Бервакыт ваннадан Галимә чыга: чәче кып-кызыл! Кутуй аптырап калды. Аннары көлешә башладык. Кутуй әйтә: «Син инде хәзер моны карага буя,— ди.— Кара чәч, зәңгәр күз бик матур булачак,—

ди.— Миңа кызыл чәчле хатын кирәкми»,— ди. Үзе көлә. Ул юморга бик оста иде. Нинди генә кәефең киткән булса да, рухыңны күтәрә, көлдерә, юата торган иде.

«Тапшырылмаган хатлар» повестен Галимә белән икебезгә кисәкләп-кисәкләп укыды. Галимә белән икәү әй мактыйбыз, әй мактыйбыз! Кутуй кеше киңәшен тыңламый иде. Бусын болай ит әле, дисәң, туры килми бит, ди иде.

Миңа Кутуй тормышымда бик күп ярдәм итте. Радиога да ул мине алып килде. Мин никтер курка идем. Әллә нинди ят, күнегелмәгән нәрсә бит. Юк, син артистка, синең тавышыңны бөтен республика ишетергә тиеш, дип үзе алып барды. Шигырьләр, хикәя сайларга булышты. Мирхәйдәр Фәйзинең «Еламыйм» дигән хикәясен укыганым хәтеремдә.

Сугыштан отпускага кайткач, мин аны кочаклап җыладым. «Кутуй, улымны төшемдә бик начар күрдем, шулай ук үләр микәнни?» — дим. Ул мине тынычландыра. Чәй эчкән арада улыма минем исемнән хат яза. Ул Фоатны бик ярата иде. Фоат та аны бик якын күрә иде. Улымның һәлак булу хәбәре килгәч, Кутуй мине юатып әйтте:

— Борчылма, мин тагын фронтка китәм,— диде.

Мин аны солдат итеп күз алдыма китерә алмыйм.

— Китмә,— дим.

— Мин дә бармасам, бүтән дә бармаса, кем сугышны бетерер,— ди. Кутуй кешенең киңәшен тыңлап тора, әмма үзенчә эшли иде.

Соңгы тапкыр сугыштан кайтканда Кутуй элеккеге Кутуй түгел иде инде. Рухсыз иде. Әллә үзенең язмышын сизенгәнме, ул бик үзгәреп кайткан иде. «Җидегәнчелек» вакытында да мин аның алай күңелсез булганын хәтерләмим. Ул үзенең гаепсез булганын, юлы туры икәнлеген белгәнгәме, күңелен төшермәгән иде. Ә хәзер алай түгел иде...

Кутуй минем күңелемдә гел саклана. Никадәр уйласам да, мин аның кимчелекләрен таба алмыйм. Башкаларда кимчелекләр күрәм мин: Фәтхи Бурнашта да, Һади Такташта да, хәтта Кашшафта да. Ә менә Кутуйның кимчелекләрен күрмим. Ул иптәшләренә гел яхшы мөнәсәбәттә булды. Беркайчан да бер кеше дә, Кутуй мине шул чакта җайсыз хәлгә куйды, яисә, миңа шундый начарлык эшләде, дип әйтә алмастыр, минемчә.

*1982, май*